# ШАХМАЙ АВЫЛЫ

*сүзләре һәм көе – Шамил Сагаутдинов*

1. Кама буйларында, туган якларымда
Искән җилләр,
Назлап күкрәгемне, арган йөрәгемне
Җилкеттеләр.

Искә төште безнең бабай салган өйнең
Нигезләре,
Таң нурлары төшкән
Тәрәзләре.

Төрле җирдә булдым, төрле илдә тордым –
Шундый язмыш.
Күп нәрсә күрсәм дә, туды йөрәгемдә
Сары сагыш.

Бик сагындым туган кырлар аша узган
Олы юлны,
Тау астында торган
Авылымны.

**Кушымта:**

Шахмай авылына кайтсам,
Шатлана күңелләрем,
Шахмай авылына кайтсам,
Яңара өметләрем.

Шахмай авылы бик ямьле, } 2 тапкыр
Шахмай авылы бик матур,
Шахмайдан башка мине ни юатыр?

2. Менә кайттым тагын, сагынып авылымның
Ак өйләрен,
Нурдай балкып торган, тиңдәше булмаган
Гүзәлләрен.

Шахмай авылым минем, куеныңда синең
Үтте яшьлек.
Сиңа булган хисем –
Ул гомерлек.

Саумы, болыннарым, сайрар кошкайларым,
Тугайларым!
Саумы, Равил абый һәм Гөлфирә апа,
Туганнарым!

Саумы, Касыйм абый һәм Миңнаһар апа,
Саумы, дуслар!
Сагындырды сезнең
Моңлы җырлар!

## Кушымта.

**Деревня Шахмайкино**

Песня посвящена деревне Шахмайкино Новошешминского района Республики Татарстан.

*Как живешь ты, край мой древний?*
*Край цветов – моя деревня!*
*Ты в душе всегда со мной.*
*Скоро ль свидимся с тобой?*